**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**БОЕРЫК**

2019 елның «21» мартында № 49

Урта гомуми белем бирү программаларын үзләштергән укучыларны дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү максатыннан, 29 декабрь, 2012 ел, № 273-ФЗ «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 59 статьясындагы 13 өлеше белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.02.2018 елда чыккан № 375-р боерыгын үтәү йөзеннән,

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә:

2019 елда бердәм дәүләт имтиханы үткәрүне тәэмин итәргә;

2019 елда урта гомуми белем бирү программалары буенча «Татар теле» һәм «Татар әдәбияты» фәннәрен үзләштергән һәм әлеге фәннәр буенча имтихан сайлаган укучылар өчен «татар теле» һәм «татар әдәбияты» фәннәреннән бердәм республика имтиханын үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә районы буенча бүлекчәсенә мәгариф өлкәсендә идарә итүче җирле үзидарә органы белән берлектә имтихан үткәрү пункты янындагы территориядә җәмәгать тәртибен саклауда һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдә кирәкле ярдәм күрсәтергә.

3. Бердәм дәүләт имтиханы һәм бердәм республика имтиханын оештыру һәм үткәрү өчен җирле бюджеттан акча бүлеп бирүне карарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р.Фәсахов**